Барлык яңалыклар www.shahrichalli.ru сайтында
«Шәһри Чаллы» № 29 (4883) | 27 апрель 2022 ел

Айрат Тәлгать улы Суфиянов 1965-1975 елда урта мәктәпне тәмамлагач, Уфаның энергетик техникумында (УЭТ) белем ала. Түбән Кама шәһәрендә елдан артык ТЭЦта эшли. 1979-1981 елларда элеккеге Куйбышев, хәзерге Самара шәһәрендә хәрби хезмәт уза. 1981-1985 елларда Коми АССРда яши. 1985 елны Татарстанның Яр Чаллы шәһәренә кайтып төпләнә. 2018 елга кадәр двигательләр заводында хезмәт куеп, лаеклы ялга чыга. Бүген Чаллының «Мәйдан» журналында проза буенча мөхәррир вазифасында. Айрат әфәнде тормыш иптәше Гөлгенә белән ике ул үстергән.
2006 елны Айрат Суфияновның «Кылычлы җил» китабы дөнья күрә. 2007 елдан ул Татарстан Язучылар берлегә әгъзасы. 2020 елны аңа «Мәйдан» журналының Илдар Юзеев премиясе бирелә. Шул ук елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган шигъри альманахта 95 шигыре дөнья күрә.

ФОТО АЙРАТ СУФИЯНОВТАН АЛЫНДЫ

Шигърият – изге ният

– Айрат, әдәбиятка нинди юллар аша килдегез?

– Мин 1958 елда Башкортостанның Балтач районы Усман авылында дөньяга килгәнмен. Әткәем Тәлгать гомер бае Ленин исемендәге колхозда агроном булып эшләде. Әнкәем Тәнзилә дә колхоздан аерылмады. Ял иткәннәрен хәтерләмим. Икесе дә хезмәт ветераннары булып лаеклы ялга чыктылар. Әткәй сугыш ветераны, өҗдәреп гармунда уйнаганы һаман күз алдымда. Мәрхүм абыем Фәрдәт гаҗәеп тәэсирле, йөрәкләргә үткәрерлек итеп Муса Җәлилнең «Вәхшәт», Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбә»сен укыганда зал басып күл чапкан, халык елаган иде. Абыйны уңышы белән яткашыбыз, сәнгатьле сөйләү остасы Айрат ага Арсланов котлаганы да бүтенгедәй күз алдымда.

Томанлы вә куркыныч төш кебек хәтеремдә: абый мине дулаган ат астыннан читкә тартып алды да, үзе чыгарга өлгерми арба астында калды. Ике урыннан аягы сынып, тугыз ай шифаханәдә ятты... Бу вакытта миңа 4 яшьләр тирәсе, абыйга 9 яшь тә тулмаган. Бернигә дә карамый ул барыбер атларны, бигрәк тә колыннарны ярата иде... Әткәй дә, газиз әнкәй дә, абыем да, биш яшь ярымда суга баткан энекәшем дәахираттә... Авыр туфраклары җиңел, Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәтендә җаннары җәннәттә булсын!

Сөекле Тукаебыз язганча: авылыбызның һәр ягында шалулап торган, җиләк-җимешкә, чикләвеккә, гөмбәгә, төрле-төрле дару үләннәренә бай катнаш урман. Наратлары күккә тиеп тора. Каеннары актан да ак.

Без үскәндә шул ук ай иде,
Тойгыларга күңел бай иде.
Кешни-кешни офык ягына
Томырылып чапкан тай иде.

Аллаһка шөкер, төп нигезебез таралмады: анда йортыбызның имин ботенлеген саклап энекәшем Илдар яши. Балачак табигать кочагында үтте. Авыл кырыннан гына Кыйгазы елгасы ага. Боз кузгалганда бозга басып йөзгән чаклар, гөрләвектә көгазь көймәләр узыштырып йөздергән, иң-иң тәкә ярлардан суга чумган бәхетле, курсусыз мизгелләр кире кайтмас өчен ерак-ераклларда, офык артларында калды... Балачактан үк әдәбиятка, гомумән, шигърияткә тартылсам да, 12 яшьтән үйларымны шигырь калыбына салырга тырышсам да, сукыр лампа якты сында күпме китап укысам да, иҗатка урау, сикәлтәле юллар аша озак килдем дисәм дөрес булыр. Юк, әкияттәге кебек ай үсәсен көн үсмадем... Әмма заводта тимерчомыр, май, тузан, төтен арасында ара-тирә югалып калгаласам да, күңелемдә шигърияткә – изге нияткә мәхәббәтем сүрелмәде. Һич кенә дә арттыру түгел, завод эчендәге шау-шу арасында да каеннар шавын, сандугачлар, тургайлар сайравын, чишмәләр челтерәвен, торналарның, кыр казларының, сыерчыкларның туган яклларыннан киткәндәге, кайткандагы авазларын да ишетә, чәчәкләрнең, мәтрүшкәләрнең хуш исен тоеп, җилдә ничек тирбалгәнәренә кадәр аермачык күреп әсәрләнә идем. Әйе, миңа зур дәрәҗәләргә ирешеп, йомшак бәрхет келәмнәргә генә басып йөрү бәхете елмаймады... Ләкин бер генә тамчы да үкенмим. Заводта эшләгәндә дә, саулыгым файда күрмәсә дә, күңелем тутыкмады. Гомер бүе гади халык белән бергә, алар язмышын үз язмышым көзәсенда, иҗатымда да чагылдырып яшәргә омтылдым... Иманым камил, башында уй-фикере, азмы-күпме сәләте булган кеше нинди халәттә дә, нинди мохиттә дә, хыял-өметләрен чиста килеш саклап, үз-үзен ихлас ачарга, халкына, гомумән, бөтен кешелек дөньясына сүз әйтергә тели. Чын-чынлап ышанам, шагыйрьлек, Сүз – Аллаһы Тәгаләдән иңгән Иман, Язмыш, Могҗиза. Форсаттан файдаланып шуны да әйтәсем килә: Бохарада озак еллар укып кайткан, 11 телне белгән, авылыбызның үкразлы мулласы булган зурәткәем Суфиян да шигырьләр яза, зурәнкәем, үзе хәзрәт кызы Кәшифә дә зур дини, дөньяви, хәтта фәнни гыйлемгә ия зат иделәр.

– Сез социаль челтәрләрне дә иҗатыгыз белән таныштырасыз. Ни өчен? Нинди юлга, максатка юнәлеш тотасыз? Шигъриятегезне комментарий язучылар ничек бәһали?

– Иҗатымны өч елга якын инде социаль челтәрләргә урнаштырам. Фейсбукта да, ВКонтактеда да заманга, милләт, тел язмышына кагылган кичерешләрем, уй-фикерләрем дөнья күрде: җәмгыйсе сигез йөздән дә күбрәк шигырь. Робагыййлар да куйдым. Сәбәбе гади. Иҗат итү – минем рухи ихтыяҗым. Ул минем яшәешемә су, һава, туфрак кебек үк мөһим, зарур, кыйммәт. Әлбәттә, халкыбыз укысын, уйлансын, уянсын, берләшсен өчен дә. Мин үз иҗатымда хаклык, дөреслек, гаделлек, изгелек эзлим. Күп кенә шигырьләремдә бөтен галәмнәрне яраткан Аллаһы Тәгаләә исеме кабатлана. Табигать, туган як, тормыш, без яшәгән чор, кешенең җан халәте, киләчәкне үйлап туган борчылулы кичерешләр, ирек, хокук, мәхәббәт киңлегендә илһамлануга да зур урын бирелгән. Кыскасы, кешелекнең асыл кыйммәтләренә йөз тотып иҗат итәргә тырышам. Ләкин, һәркемгә дә йогынты ясаган сәяси вазгыятьне дә читләп узганым юк. Гаделлеккә, тигезлеккә, якты лыкка, яхшылыкка кешелек дөньясын коткарачак матурлыкка, иминлеккә сабыйларча беркатлылык белән инанып, өметләнеп язам... Үз укучымны таптым дип үйлыйм. Алар арасында шигъриятне тирән аңлап, анализ ясаучылар шактый күп булуы, иҗатымны бәһаләп уңай комментарийлар язулары күңелне сөендерә.

– Кайберәүләр сезнең иҗатка күбрәк пессимизм, күңел төшенкелеге хас диләр. Ни өчен? Гомумән, сезнең күңелне нәрсә кузгата?

– Билгеле, шагыйрьне, шигырьне төрле кеше төрле күзлектән карап кабул итә. Беркемне дә гаепләргә җыенмыйм. Ләкин шуны әйтергә теләшмен: тойгаларымны, күргәнемне, аңлаганымны (хакыйкатькә дәгъва итмим) язам. Кемдер пессимист мөһере суга икән, ихтыяры, суксын. Ниндидер катгый нәтиҗә ясар өчен минем һәр шигыремне, бөтен иҗатымны үйланып, игътибарлап укыргa һәм... аңларга кирәк. Бары шул... Дөньяга да, заманга да, тормышка да төрле яссылыктан карыйм. Минем караш башкаларныкы белән тәңгәл дә килмәскә мөмкин. Бәлки мин оптимист та, пессимист та, романтик та түгелмендер. Ләкин минем рухи халәтем матурлыкка, ямьгә, мәрхәмәткә күз йомган, кояшка артын борган битарафлык та түгел... түгел... «Нәфрәттән дә мин мәхәббәт эзлим». Хәер, бөтен иҗатымны кайчандыр барлап, тәфсилләп өйрәнсәләр, анда минем җанның һәрбер хәрәкәте, хәтта күз күрмәгән сулышы да чагылдырылган. Нигездә, мин үземне чынбарлыкны язучы дип исәплим. Бу катлаулы, болгавыр заманда кешеләргә дөреслек кирәк. Ялтыравык, эче калтыравык, шалтыравык ялганга табынып йөтәлү – фажига. Күңелне кузгаткан вакыйгалар, тәэсирләр күп. Хаксызлык, затсызлык, оятсызлык, ялагайлык, комсызлык, хокуксызлык, кешеләрдәге битарафлык, гамьсезлек, шәфкатсезлек, гаделсезлек, имансызлык, ерткычлык. Болар барысы да инсаният дөньясына тискәре йогынты ясаган шайтани көчнең төп билгеләре. Дөньяның начар, караңгы ягын гына күрү дә нигездән дөрес түгел. Кара төннән соң елмаеп таң ата, яңа көн туа. Салкын кыштан соң җылы агым булып яз кила. Бернигә дә карамый кошлар сайрый, кубәләкләр оча. Тормыш ничек акса, шулай ага. Ямьсезлек – матурлык, батырлык – куркаклык, явызлык – изгелек. Ниншлисең, тормыш тулаем каршылыклар корылган...

– Сезнең сүзләрә язылган җырлар да бар. Кемнәр башкара? Сез аларны сатасызмы?

– Әйе, махсус җыр текстлары язмасам да, 30га якын шигыремне көйгә салдылар. Бу өлкәдә аеруча талантлы, милләтпәрвәр җырчы-композитор Флүрә Талипова активлыгы белән аерылып тора. Ул «Әйтмә миңа», «Өгәр язмыш», «Хәтер», «Йөрәкләргә шакыйм», «Үсман авылы»на кой язды. Равил Галиев «Кыр казлары»н, яшь җырчы Азалия «Очам, очам»ны башкаралар. Башкортостан җырчысы Гүзәл Әхмәтова «Әнкәемә», «Тәнге абага», «Мәхәббәт күпере»н халыкка ирештерде. «Кайттым туган ягымa» Илнар Сәйфиев, Салават Фәтхетдинов репертуарында да бар. Көен Наил Мортазин ясады. Якташым, талантлы җырчы-композитор Алсу Мортазина (Шакирә) күп кенә шигырьләремә кой язып, үзе үк халкыбызга да җиткерде. Асылъяр «Дөнья матур» (Фәрит Хатыйпов көе), Алсу Хәбибуллина «Сөймим димә»не (Алсу Мортазина көе), «Гөлләргә сыен»ны (Ринат Гобәйдуллин көе) Сиринә Зәйнетдинова башкара. Минем башкаручылардан акча сораганым да, сатканым да юк. Чөнки миңа алыпсатарлык сәләте тумыштан бөтенләй бирелмәгән.

– Сез ни өчендер китап чыгаруны суздыгыз. Сәбәбе бармы?

– Матбугатта шигырьләрем даими басылып килсә дә, чынлап та, китап чыгару шактый озакка сузылды. Сәбәбен үземнең артык акрын кыймылдаудан, үз-үземне тиешенча өештырып бетерә алмаудан һәм... ялкаулыгымнан күрәм. Беренче «Кылычлы җил» дип исемләнгән китабым Чаллы язучылар берлегеләрәисе Факил абый Сафинның җылы күлы белән нәшриятка илтеп тапшырганнан соң дөньяга аваз салды. 2003 елны «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә китапка керәчәк шигырьләрнең кайберләрен укыган идем. Ул вакытта талантлы шагыйрьләр Рәшит абый Бәшәр, Фируз ханым Җәмалетдинова иҗатымны хуплап, китап итеп түпларга киңәш бирделәр. Ярдәм иттеләр. Зур рәхмәт аларга. Китабым дөнья күрепә, күпмедер вакыт узганнан соң, чорыбызның титан шәхесе, шагыйрь, прозаик, публицист, милләт каршында олы хезмәт күрсәткән Айдар ага Хәлимнең «Шәһри Чаллы» газетасында минем иҗатыма багышланган «Ак биләүләр моңы» дигән мәкаләсе басылу минем өчен сөенеч булды. Әйтергә кирәк, минем башлангыч иҗатыма да ул канат куйды. 40 еллар чамасы әлек үк: «Күп укы, күп бел, бал кортыдай тырыш, тынгысыз бул, куан һәм куандыр» – дип язган иде ул. Бу күпкырлы шәхескә аерым рәхмәтем!

– Кайсы шагыйрь күңелегезгә хуш, рухи дөньягызга якын, кадерле? Кемнәр алар?

– Күңелемне канәгатьләндергән шагыйрьләр бихисап. Һәрберсе дә олы, кабатланмас, серле бер дөнья. Чишмә башыбыз Кол Галигә тоташса да, гадәттә, без Тукайдан башлыйбыз. Һәм... бу дөрес шикелле. Фани дөньяда нибары 27 ел яшәп, туган халкыныңь бөтен кайгы-газабын, хәсрәтен, борчылуларын, үй-фикерләрен ябык кына иңнәрендә күтәреп, бәһаләп бетермәслек иҗади мирас калдырып, рухи юлбашчыга әверелгән бөек, дөньякүләм билгеле сирәк шәхес. Тагын кемнәрне атарга мөмкин? Дәрдемәнд, Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким. Бүтенге көндәге шагыйрьләрдән дә игътибарга, өйтәмрга лаеклар аз түгел. Чаллы шагыйрьләре Кадыйр Сибгатуллин, Айдар Хәлим, Данис Хәйруллин, Рәшит Бәшәр, Факил Сафин, Галиәхмәт Шаһи, Габденур Сәлим. Алардан яшьрәк дөньяны: Рәзинә Мөхияр, Зөләйха Миңнаҗәва, Әлфия Ситдыйкова, Сирень Якупова, Лилия Фәттахова, Лилия Гыйбадуллина. Өммәтебезнең сакчысы, яклаучысы Фәүзия апа Бәйрәмовага аерым тукталасым килә. Халкыбызның тамырларын, үткәндәге бөеклегенең җепселларенә кадәр барлап, ачынып та, ачылып та төрле яклап та өйрәнгән, искиткеч рухи көчкә, батырлыкка ия булган, прозасы, шигърияте, шәхесенең зурлыгы белән дә сокландырган фидакарь зат!

Күңел күзен башкалабыз Казанга күчерсәм, анда да шигърият казаны кайнап тора... Үрнәк алырлык шагыйрьләр әле дә бар, булган һәм... булачак!

Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Марсель Галиев, Разил Валиев, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Җәүдәт Сөләйман, Зөлфәт Хәким, Рәмис Әймәт. Кайта-кайта Саҗидә Сөләймановны укыйм. Хатын-кызларыбыздан Нәҗибә Сафинаны, Клара Булатованы, Фируз Ә Җамалетдинованы, Сания Әхмәтҗанованы, Рифә Рахманны, Гөлүсә Батталованы, Луиза Янсуарны, Ландыш Габдрахмановны билгеләп үтәсем килә. Яшьләр арасында Рүзәл Мөхәмәтшин, Фәнил Гыйлаҗев, Ленар Шәех. Бакыйлыкка күчкән мәртәбәле абруй казанган шагыйрьләребездән Илдар Юзеев, Әнгам Атнабаев, Нәҗар Нәҗми, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, Фәнис Яруллин, Гакыйль Сәгыйров, Харрас Әюп, Зөлфәт Маликов, Мөдәррис Әгъләм, Роберт Миңнуллин, Илдус Гыйлаҗев, Наис Гамбәр, Гәрәй Рәхим, Рифкатъ Закиров.

Урыс шагыйрьләреннән тамыры голланд милләтенә тоташкан Лермонтовны мөкиббән китеп, яратып укыйм. Пушкинны, Есенинны, Тютчев һәм Афанасий Фетны. Чит ил шагыйрьләреннән Джордж Байрон, Гете, Гейне, Вильям Шекспир.

Прозаикларыбыздан Әмирхан Еникине, Фатих Хөснине, Мөхәммәт Мәһдиевне, Аяз Гыйлаҗәвне, Нурихан Фәттахны, Вахит Имамовны, Факил Сафинны яратып укыйм. Билгеле, бу тулы исемлек түгел...

– Быел китабыгыз нәшрият планына керде, диделәр. Нинди исем астында? Көтәсезме?

– Әлбәттә, көтәм. Ачымы, татлымы, тәчеме, иҗат җимешемне өммәттәшләрем дә татыргa тиеш. Үзгәреш булмаса, китапның мөхәррире, чорыбызның мин хөрмәт иткән күренекле шагыйре – Газинур Морат. Китапның исемен ике вариантта бирдем: беренчесе – «Өмет догасы», икенчесе – «Өченче сулыш». Газинур кайсын кулай күрер. Аңа тулаем ышанам. Китабымны чыгаруны сорап нәшриятка гариза язучы Факил абый Сафинга, Газинур Мораткa, нәшриятка үзенең хуплау тавышын ирештергән Вахит абый Имамовка, иҗатыма уңай карашта булган, бүгенге рәисебез, депутат, халык шагыйре Ркаил Зәйдуллага китабым дөньяга чыгарына ышанган, өметләнган хәлдә чиксез рәхмәтемне юллыйм.

– Киләчәккә нинди планнар белән яшисез?

– Алдагысын Аллаһы Тәгаләә белә. Алда гомер булса, прозада каләм көчемне сынарга ниятем бар.

– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Сау-сәламәт, бәхетле, милләтебезне хөрмәтләүче, үстерүче булыгыз! Халкыбыз бердәмлектә җанын да, динен дә, телен, гореф-гадәтләрен дә, үз йөзен дә саклап, алгарышка ирешсен.

Р. Мәхмүтова сөйләште.